**«Татар матбугаты – балалар өчен»**

«Ялкын» – татар телендә чыгучы бердәнбер балалар һәм яшүсмерләр журналы. 1924 елдан бирле чыга. Абдулла Алиш, Муса Җәлил премияләре лауреаты. Баш мөхәррире — Илназ Фазуллин. 1924 елның 20 мартында Мәскәүдә «Кечкенә иптәшләр» дип аталучы балалар журналының беренче саны дөнья күрә. Журнал гарәп язуында була. 1928 елдан «Кечкенә иптәшләр» латин графикасына күчеп, «Октябрь баласы» дип атала башлый. 1933 елда журнал Казанга кайта, «Пионер каләме»нә әверелә. 1941 елда, сугыш башлангач, журнал чыгудан туктала. Сугыш беткәч,1952 нче елда ул «Пионер» исеме белән янә дөнья күрә. Ә 1957 елда журналның исеме «Ялкын» га үзгәртелә. «Ялкын» журналын балалар һәм яшүсмерләр генә түгел, ә өлкәннәр дә бик яхшы беләләр. Нигә дигәндә «Ялкын» журналы – аларның да балачак журналлары ул. Кемдер аны ай саен зарыгып көтеп алып укып барган, кемдер журнал битләрендә үзенең беренче иҗат җимешләрен урнаштырган, ә кемдер «Ялкын» оештырган чараларның активисты булган. Ә кайберәүләр әле бүген дә үз китапханәсендә бу журналны саклап киләдер. Вакыт узган саен журнал матурлана, заманлаша бара. Аның тышлыгы гына түгел эчке ягы да үзгәрде, матурайды. Журнал битләрендә бүгенге көн яшүсмерләр өчен кызыклы булган яңа сәхифәләр өстәлә. «Ачыш», «Шәхес» сәхифәләрендә үсмерләр энергияле, актив, талантлы яшьләр белән таныша алалар. “Сер тулы” дөнья” сәхифәсендә укучылар үзләре өчен кызыклы ачышлар ясый алалар. “Оялчан алма” сәхифәсен укып, яшьтәшләренең уй-фикерләрен ишетә, үзләрен борчыган сорауларга җаваплар табарга мөмкин.

«Сабантуй» журналы кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен тәкъдим ителә. «Сабантуй» журналы 1924 елның 10 нчы октябрендә 1500 данә тираж белән чыга башлаган «Яшь ленинчы» газетасының лаеклы дәвамчысы ул. «Яшь ленинчы» сугышка кадәр дә, сугыштан соң да күп тиражлы газет саналган. Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, 1941 елда «Сабантуй» чыгудан туктап торган. 1961 елда Венера Ихсанова балалар газетасын яңадан торгызган. Журналда Венера Ихсановадан соң , Роза Туфитуллова, Роберт Миңнуллин баш мөхәррир булып эшлиләр. 1991 елда, Роберт Миңнуллин чорында, «Яшь ленинчы» «Сабантуй» исеме белән чыга башлый. Журналда «Канатлы ат », «Иҗат мәйданы», «Халык авыз иҗаты» һәм башка кызыклы сәхифәләр эшләп килә. «Сабантуй» укучысы әлифбаны белә, ул үзе дә иҗат итә. Шулай итеп, актив һәм сәләтле булган балалар үзләренең иҗат эшләрен дә журнал битләрендә күрә алалар. Журналны укып бераз баш эшләтеп алырга да, төрле кул эшләнмәләре ясап, якыннарыбызны сөендерергә дә була. Илебез күләмендә ел саен уздырыла торган «Россиянең

биш яхшы этник басмасы- 2019» бәйгесендә «Сабантуй» журналы «Иң яхшы балалар басмасы» номинациясендә җиңү яулаган иде.

«Салават күпере» » журналы 1990 нчы елның март аеннан бирле чыга. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен, өлкәннәр тарафыннан балаларга уку өчен тәкъдим ителә. Журнал битләрендә халык әкиятләре, күренекле татар балалар язучыларының әсәрләре, әйләнә – тирә дөнья хәлләре, татар әдипләренең тормышы, эшчәнлеге турында даими басылып килә. Аерым балар язучысы яки шагыйре турында махсус саннар чыгып килә. Алар кызыклы , мавыктыргыч матур кечкенә китапчыклар рәвешендә эшләнгән. «Салават күпере» нең тышкы формасы да уңай якка үзгәрде. Мәче яисә гөмбә формасында эшләнгән журналлар сабыйларның игътибарын үзенә җәлеп итә. Мәсәлән апрель санында журнал сәгать формасында чыкты. Бу балалар өчен вакытны өйрәнергә бик җайлы ысул. Балалар үзләренең иҗат эшләрен дә журнал битләрендә күрә алалар. Моның өчен рәсем ясап, яисә шигырь язып журнал редакциясенә генә җибәрәсе. Әгәр дә балаларыбызның татарча белүләрен , аларга милли тәрбия бирәсебез килә икән, татар телендә чыгып килүче «Ялкын», «Салават күпере», «Сабантуй» кебек басмалар кече яшьтән үк аларның өстәл китабы булырга тиеш дип уйлыйм мин.

Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы балалар китапханәсе – 3 нче филиал китапханәчесе Гатауллина Нәҗия Аксән кызы.